6+

ГӘРӘЙ РӘХИМ

# ИСКЕ САМАВЫР ТОРБАСЫ




ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

УДК 821.512.145-1-93/3-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4/5
Р95

Рәссамы *Рөстәм Хәбибуллин*

**Рәхим, Г. В.**

Р95 Иске самавыр торбасы : балалар өчен шигырьләр һәм хикәяләр / Гәрәй Рәхим [рәссамы Р. Хәбибуллин]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2018. – 90 б.
ISBN 978-5-298-03609-2

Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гәрәй Рәхимнең әлеге китабына балалар өчен язылган шигырьләре һәм хикәяләре тупланды.

УДК 821.512.145-1-93/3-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4/5

ISBN 978-5-298-03609-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2018
© Родионов Г. В., 2018

# АЛМА САТУЧЫ АПА ЯНЫНДА



Тротуарда бер апа
Кып-кызыл алма сата.
Карап торам аптырап.
Тезелгән озын чират:
Әбиләр дә бар монда,
Бабайлар да бар монда,
Малайлар да бар монда,
Маэмайлар да бар монда.
Песи дә бар чиратта,
Күсе дә бар чиратта,
Хәтта атлар да килгән
Ипподром дигән җирдән.
Ике маймыл басканнар
(Зоопарктан качканнар).
Күзлек кигән карт карга
Килеп басты иң алга...
Аптырама бу хәлгә,
Чынын әйтсәм әгәр дә –
Бу чиратны мин үзем дә
Күрүен һич күрмәдем,
Күрдем, диеп, болай гына,
Юри генә сөйләдем...
Тик чыннан да урамда
Шушындый чират торса,
Кызык булмас идемени
Кызык сөйгән кешегә?!
Ягъни минем ишегә,
Яки синең ишегә.

# КУРАЙЛАР ХОРЫ

Әрәмәдән чуар көпшә
Җыеп алып кайттык та
Ясадык без бик күп курай
Төрле-төрле тавышка.
Кайсы калын итеп, кайсы
Нечкә итеп сызгыра.
Җаен белсәң, барысы да
Матур көйләр сыздыра.
Авылдагы бөтен малай
Курайчы малай булды,
Кичләрен һәрбер урамга
Курай моңнары тулды.
Бер урамда яңг(ы)рап тора
Сандугачлар сайравы,
Ә берсеннән ишетелә
Карурманнар шаулавы.
Без бик күп көйләр өйрәндек,
Олылар тыңлап торды.
Әрәмәдә үскән икән
Моңлы курайлар хоры.

# МИН ЯСАГАН КАР БАБАЙ

Мин ясаган кар бабайга
Бөтен урам сөенә,
Чөнки ул чын кеше кебек
Сөйләшә, җырлый белә.
Йә кинәт көлеп җибәрә,
Скрипка да сыздыра.
Йә ул, сандугач шикелле,
Чут-чут дип сайрап тора.
Матур итеп шигырь укый,
Мәзәк сөйләп көлдерә.
Хәтта һава торышын да
Бер көн алдан белдерә.
Бу кар бабайны ясавы
Кыен булмады һич тә.
Нәни транзисторымны
Куеп калдырдым эчкә.





# ТИМЕР ТОРНА

*(Тизәйткеч)*

Иртән торып карап йөрдем
Өй түбәсе-чорманы.
Шунда күрдем чормадагы
Нәни тимер торнаны.
Аннан ачы торма бирдем
Чормадагы торнага.
Ә торманы кадап алдым
Иске тимер тырмага.
Тырмадагы торма белән
Чормадагы торнаны
Сыйласам да, тимер торна
Урыныннан тормады.

# ЯФРАКТАГЫ НОТА

Укытучы апа безгә
Ноталар бүлеп бирде.
– Бүгенге җырның исеме –
«Көзне озату», – диде.
Ә мин бер яфрак алдым да
Шуңа карап җырладым.
Бер тамчы да ялгышмадым
Һәм артка да калмадым.
Чөнки бит көз безнең яктан
Китеп барган чагында,
Зур-зур сары яфракларга
Көен язып калдырган.





# ӘТӘЧЛӘРЕМ

Әтәчебезнең рәсемен
Ясап куйдым бер калайга.
Шундый матур килеп чыкты –
Шаккаттылар бар малайлар.
Аннары мин ул рәсемне
Иплəп кенә кисеп алдым.
Килеп чыкты калай әтәч –
Мин үзем дә хәйран калдым.
Үзебезнең чын әтәч тә
Бик ошатты минем эшне.
Озак кына карап торды
Һәм: «Кикрикүк!» – дип эндәште.

Ләкин рәсемдәге әтәч
Аңа һич тә җавап бирми.
Тып-тын гына басып тора –
Ул шул әтәч телен белми.
Мин аны өй түбәсенә
Кадап куйдым аптырагач.
«Флюгер булырсың, – дидем, –
Әтәч телен аңламагач».
Әле алга, әле артка,
Уңга, сулга әйләнде ул.
Шулай итеп, озакламый
Җилләр телен өйрәнде ул.
Тере әтәч хәбәр итсә
Таң атар вакыт җиткәнне –
Калай әтәч әйтеп тора
Кайсы яктан җил искәнне.

# Эчтәлек

## Шигырьләр


Алма сатучы апа янында . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Курайлар хоры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Мин ясаган кар бабай . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Тимер торна . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Яфрактагы нота. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Әтәчләрем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Каргалар шәһәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Атлас һәм Атлант . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Буян һәм куян . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Кызык эзлим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Кычыткан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Безнең тауда. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Грипп йоктырган Бака . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Саескан өйрәтәм. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Яшенле яңгыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Ялкау малай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Язгы әкият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Минем тырысым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Юри генә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Безнең урам кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Гөмбә җыярга бардым . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Шушы язгы мизгелдә . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Җебек түгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Мәктәптән кайткан чакта . . . . . . . . . . . . . . . 30
Такыялар. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Тәнәфес . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32


## Хикәяләр


Иске самавыр торбасы . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Тау бабай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Чәчәк сатучы малай. . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
Дустыбыз Актырнак. . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Алмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Сүз бирдем. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82